| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**12.02.2021** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№266** |

Зеленодольск муниципаль районы белем бирү оешмалары укучыларына һәм укытучыларына фән олимпиадаларында катнашу йомгаклары һәм белем бирү оешмаларын чыгарылыш укучыларның бердәм дәүләт имтиханы рәвешендә дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча грант ярдәме турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Гамәлдәге законнар нигезендә, укучыларны кызыксындыру максатларында - гомуми белем бирү фәннәреннән Республика фән олимпиадаларыннан, Бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль, региональ һәм Бөтенроссия этаплары җиңүчеләрен һәм призерларны , бердәм дәүләт имтиханы формасында белем бирү оешмаларын тәмамлаучыларның дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча, шулай ук гомуми белем бирү оешмалары укытучыларының гомуми белем бирү предметлары буенча Республика фән олимпиадаларыннан, Бөтенроссия олимпиадаларының муниципаль, региональ һәм Бөтенроссия этапларында катнашу йомгаклары буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 15 маендагы 940 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы белем бирү оешмалары укучыларына һәм укытучыларына фән олимпиадаларында катнашу йомгаклары һәм белем бирү оешмаларын чыгарылыш укучыларның бердәм дәүләт имтиханы рәвешендә дәүләт йомгаклау аттестациясен узу йомгаклары буенча грант ярдәме турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп түбәндәге редакциядә бәян итәргә :

1.1. «п.2.1. Һәр кандидат буенча материаллар белем бирү оешмалары тарафыннан Мәгариф идарәсенә тапшырыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

- кандидат турында белешмәләр (фамилиясе, исеме, атасының исеме; көне, ае, туган елы; мәгариф оешмасы исеме, классы; теркәлү һәм яшәү урыны, телефоны; паспорт яки туу турында таныклык күчермәсе);
- олимпиадаларда катнашу нәтиҗәләрен раслый торган документларның таныкланган күчермәләре, бердәм дәүләт имтиханын тапшыру беркетмәләренең күчермәләре;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә».

1.2. «п.2.2. Һәр кандидат буенча материаллар белем бирү оешмалары тарафыннан Мәгариф идарәсенә тапшырыла һәм үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:
- кандидат турында белешмә (фамилиясе, исеме, атасының исеме; көне, ае, туган елы; мәгариф оешмасы исеме, классы; теркәлү һәм яшәү урыны, телефоны; паспорт яки туу турында таныклык күчермәсе);
- олимпиадаларда катнашу нәтиҗәләрен раслый торган документларның таныкланган күчермәләре;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигына массакүләм мәгълүмат чараларында, Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны җитәкче урынбасары – Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе башлыгы Р.В. Афанасьевага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев